УКАЗ
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
УКАЗЫ

Донецк Халык Республикасы, Луганск Халык Республикасы һәм Украина территорияләрендә уздырыла торган махсус хәрби операциядә катнашулары нәтиҗәсендә һәлак булган (вафат булган) Россия Федерациясе милли гвардиясе гаскәрләре хәрби хезмәткәрләренең һәм аларда хезмәт иткән затларның гаилә әгъзаларына бер тапкыр бирелә торган акчалата түләү турында

2022 елның 24 февраленнән Донецк Халык Республикасы, Луганск Халык Республикасы һәм Украина территорияләрендә уздырыла торган махсус хәрби операциядә катнашулары нәтиҗәсендә һәлак булган (вафат булган) Россия Федерациясе милли гвардиясе гаскәрләре хәрби хезмәткәрләренең һәм аларда хезмәт иткән затларның гаилә әгъзаларына матди ярдәм күрсәтү максатларында **карар бирәм:**

1. 2022 елның 24 февраленнән Донецк Халык Республикасы, Луганск Халык Республикасы һәм Украина территорияләрендә уздырыла торган махсус хәрби операциядә катнашулары нәтиҗәсендә һәлак булган (вафат булган) Россия Федерациясе милли гвардиясе гаскәрләре хәрби хезмәткәрләренең һәм аларда хезмәт иткән һәм махсус полиция званиесе булган затларның (алга таба – хәрби хезмәткәрләр) гаилә әгъзаларына 2 млн сум күләмендә, әлеге Указның 2 пунктында күрсәтелгән һәр затка бертигез өлештә бер тапкыр бирелә торган акчалата түләү (алга таба – бер тапкыр бирелә торган акчалата түләү) билгеләргә.

2. Бер тапкыр бирелә торган акчалата түләү түбәндәгеләргә бирелә дип билгеләргә:

хәрби хезмәткәрнең һәлак булган (вафат булган) көненә аның белән теркәлгән никахта торган хатынына (иренә);

хәрби хезмәткәрнең әти-әнисенә (аны уллыкка яки кызлыкка алучыларга);

хәрби хезмәткәргә карата ул балигълык чорына җиткәнче кимендә биш ел дәвамында опекунлык (попечительлек) вазыйфаларын үтәгән затларга;

хәрби хезмәткәрнең балаларына.

3. Әлеге Указны үтәү максатларын күздә тотып, һәлак булган (вафат булган) хәрби хезмәткәрләргә туган яисә яшәгән урыны Татарстан

Республикасы территориясендә булган яки Татарстан Республикасы территориясендә җирләнгән гражданнар кертелә.

4. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына:

бер тапкыр бирелә торган акчалата түләүне башкару тәртибен расларга;

әлеге Указны үтәү белән бәйле чыгымнарны финанслауны билгеләнгән тәртиптә тәэмин итәргә, шулай ук аны гамәлгә ашыру буенча башка карарлар кабул итәргә.

5. Әлеге Указ аңа кул куйган көннән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы Президенты **Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2022 ел, 04 апрель
№ ПУ-233